РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«23» сентябрь 2020 е. Олы Кайбыч ав. № 5

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү турында» 2020 елның 15 нче июнендәге 242 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының бер тапкыр күләменә исәпләнә. Шул ук вакытта авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә»;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү турында» нигезләмәнең 2 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

4.Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе А. И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2020 елның «23» 09.
5 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләре күләмнәре**

| Вазыйфа исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 30442 |
| Башлык урынбасары | 27398 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 27398 |